Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 36 (49)
13 декабрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**7 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы һәм «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм эшмәкәрләр ассоциациясе» төбәк берләшмәсе арасында **КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ**. Ике як югары квалификацияле кадрлар әзерләү өлкәсендә партнерлык мөнәсәбәтләрен һәм уртак чаралар оештыру, Татарстан икътисадының инновацион мәсьәләләрен хәл итү өчен югары уку йортларының фәнни берләшмәсе сәнәгать предприятиеләре белән үзара бәйләнешне активлаштыру турында сүз куешты.

• • • •

**10 ДЕКАБРЬДӘ** КФУның Алабуга институты актлар залында «Изгелек планетасы» инвалид балалар һәм яшьләр региональ җәмәгатьчелек берләшмәсе оештырган **ХӘЙРИЯ КОНЦЕРТЫ БУЛДЫ**. Оештыручылар тамашачыларны үзләренең җырбиюләре белән шатландырдылар. Балалар үз куллары белән эшләгән уенчык һәм картиналар күргәзмәсе оештырылган иде. Теләгән һәркем аларны сатып та ала алды.

• • • •

**10 ДЕКАБРЬДӘ** Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының актлар залында «КФУда коррупциягә каршы көрәш. Тәҗрибә һәм перспективалар» темасына багышланган **ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ БУЛДЫ**. Оештыручыларның төп максатлары – студентлар арасында коррупциягә карата тискәре караш булдыру.

• • • •

**11 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** КФУ ректоры Илшат Гафуров катнашында **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ ҮТТЕ**.

Башта ректор Россия Президенты Владимир Путинның ышанычлылары белән узган очрашу турында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, В.Путинның бөтен президентлык итү чорында ышанычлы затлар институтын саклау кабул ителгән. «Алар дәүләт җитәкчесе һәм гади халык арасында әһәмиятле роль башкара», – диде җитәкче.

Университет эшләренә килгәндә, ректор Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә турында башка җиргә күчә дигән имеш-мимешләрнең дөрес булмавын әйтте.

Алга таба фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев Идел буе федераль округы төбәкләрендә югары белем бирү системасын үзгәртүгә бәйле РФ мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре катнашында узган җыелыш нәтиҗәләре белән таныштырды.

Ю.Либиг исемендәге Гиссен университеты һәм КФУ арасындагы хезмәттәшлек турында Фундаменталь медицина һәм биология институтының микробиология кафедрасы җитәкчесе Ольга Ильинская сөйләде. Партнерлык кысаларында студентлар алмашы, фәнни килешүләр тормышка ашырылачак.

Фундаменталь медицина һәм биология институтының Үсеш программасы белән директор Андрей Киясов таныштырды. Институт белем бирү процессын модернизацияләү, яңа лаборатор корпус һәм фундаменталь үзәк ачылу – институттагы иң мөһим үзгәрешләр.

• • • •

Шушы көннәрдә Казан федераль университетына **ШАНХАЙ АСТРОНОМИК ОБСЕРВАТОРИЯСЕ ГАЛИМНӘРЕ КИЛДЕ**. Очрашуда киләсе елга ике югары уку йорты арасында хезмәттәшлек турында (уртак публикацияләр һәм докладлар булдыру) сүз алып бардылар.

• • • •

**11 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Алабуга институтында Россия Федерациясе Конституциясе Көненә багышланган **«КОНСТИТУЦИЯ ЯШЬТӘШЕ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ЧАРА УЗДЫ**. «Парламент сәгате» дәүләтебезнең төп законына багышланган иде. Катнашучылар өчен тарих һәм юриспруденция факультеты студентлары кечкенә генә викторина да уздырдылар.

• • • •

**БҮГЕН** «Халыкара медиапроектлар, Глобаль челтәрләр, Көнчыгыш һәм Көнбатышның мәгълүмати трендлары» дип исемләнгән **VI ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ**. Чараның төп максаты: Глобаль челтәрләрнең үсеше контекстында заманча мультимедияле медиасистемаларны, медиапространствода халыкара багланышлар һәм журналистлык мәдәнияте интеграциясен өйрәнү һәм камилләштерү.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотолары

# Яңа ниятләр

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

12 декабрь көнне Педагогика һәм психология институты җитәкчелеге һәм коллективы белән ректор Илшат Гафуров очрашты.

Зур үзгәрешләр кичереп, яңа составта эшли башлаганга бик аз вакыт үтсә дә, ректорыбыз һәр институт, аның хезмәткәрләре, студентлары белән тыгыз элемтәдә яши. Бу очрашуда рәсми утырышка кадәр, Илшат Гафуров башта институт үзәкләре, лабораторияләр белән танышты. КФУның Үсеш программасы буенча Педагогика һәм психология институтында сәламәтлегендә зур кимчелекләр булган балалар өчен махсус үзәк ачылган. Биредә заманча җиһазлар, балалар өчен уенчыклар бар. Башта студентлар шөгыльләнсә, киләсе елга үзәктә балалар укый башлаячак. Аның үзенчәлеге дә шунда: биредәге аппаратлар хәтта иң авыр балалар белән дә эшләү мөмкинлеге тудыра. Уку елы ахырына кадәр, үзәккә махсус камералар куелачак. Алар башка аудиторияләрдә утыручы студентларга мондагы эш барышы, балаларның үз-үзен тотышын күзәтеп тора алачак.

Межлаук адресы буенча урнашкан бинада химия лабораторияләре дә урын алган. Ректор: «Сез 2014 елда ачылачак Химия институтының яңа бинасына күчәчәксез», – диде. Шулай ук институт белән танышканда, педагогик белем бирүгә бәйле Тарих музее ясау, Wi-Fi булган уку залы ачу, электрон китапханәгә керү мөмкинлеге булдыру кебек тәкъдимнәр әйтте.

КФУның педагогик белем бирү буенча рейтингы соңгы елларда 54 урыннан 18 урынга күтәрелгән. Үз чыгышында Педагогика һәм психология институты директоры Айдар Кәлимуллин быел бюджет урыннарына күпләп кабул итүләре турында әйтте. «Ике бик зур һәм көчле бүлегебез бар. Без педагогик белем бирү буенча яңа модель булдыру өстендә эшлибез. Башка уку йортындагы коллегаларыбыз да шуңа таяна», – диде.

«Үзгәрешләр кичерсәк тә, уңышларыбыз зур. Күптән түгел Саратовта узган җыелышта РФның мәгариф һәм фән министры Д.Ливанов та КФУ үрнәгендә чыгыш ясады», – дип сүз башлады ректор һәм уку йортыбыз эшчәнлеге турында презентация тәкъдим итте. 48 меңгә якын студент белем ала торган университет төп инновацион юнәлешләргә таяна. Беренче чиратта, нефть табу, аны эшкәртү тора. Икенчедән, биотехнология, фармацевтика һәм биомедицина, өченчедән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, дүртенчедән, комплекслы социо-гуманитар тикшеренүләр мөһим роль уйный. Бездә һәрдаим яңа лабораторияләр, тикшеренү үзәкләре ачыла. Киләчәктә үз житештерүебез булачак, димәк, үзебез ясыйбыз, үзебез кулланабыз.

**Ахыры 2нче биттә.**

## • Бездә кунак бар

# Ирек тә чикләнгән булырга тиеш!

**Рифат СӘЛАХ**

11 декабрь көнне КФУның юридик факультетына интеллектуаль милек хокукы буенча белгеч, юридик фәннәр докторы, профессор, Россия Дәүләт интеллектуаль милек академиясе ректоры Иван Близнец килде.

Кунак яшь хокук белгечләренә интеллектуаль милек хокукы буенча лекция укыды. Дәрәҗәле профессор белән очрашуда юрфак студентлары белән беррәттән, юридик факультетның декан урынбасары Лилия Бакулина һәм үзе дә интеллектуаль милек буенча мөгаллимә Роза Ситдыйкова да бар иде.

Иван Близнец сүзләренчә, Россиядә интеллектуаль милеккә, авторлык хокукларына игътибар артып бара. Советлар берлеге вакытында, илебез бу өлкәдәге бер генә халыкара документны да имзаламаган. СССР таркалгач кына, Россия Вена конвенциясенә кул куйган, авторлык һәм эргәдәш хокуклар турында канун барлыкка килгән. 2011 елда әлеге кануннар урынына РФ Гражданнар кодексының дүртенче кисәге буларак кабул ителгән. Интеллектуаль милеккә уңай караш артуның тагын бер дәлиле аспирантлар икән.

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

# Яңа ниятләр

**Башы 1нче биттә.**

Ректор яңа укыту методикаларын булдыру теләген җиткереп: «Такта, акбур, укытучы, язып утыра торган укучы кебек искелекләрдән арынырга кирәк. Заман атлый, XIX-XX гасырларда шундый тәртип булган. БДИ нәтиҗәләре дә дәрестә алган белем буенча гына түгел, ә индивидуаль шөгыльләнгәч яхшырак була», – диде.

Ректор хезмәттәшләренең сорауларына да җавап бирергә өлгерде. Педагог-психологларның әллә ни зур проблемалары да юк кебек. Алар күбрәк рәхмәт сүзләре, теләк-тәкъдимнәр җиткерде. Ләкин шулай да... Кайбер укытучылар кабинетлар җитмәүдән зарланды. Финанс һәм икътисад институтында (элекке КДФИИ) бераз катлаулы икән. Әйтик, укытучылар өс киемнәрен, сумкаларын үзләре белән күтәреп йөрергә мәҗбүр. Шуңа күрә институтара кабинет ясарга дигән теләк яңгырады. Ректор бу тәкъдимне кабул итеп, хәтта магистр һәм аспирантлар өчен дә аерым бүлмә булачагын әйтте. Шулай ук университетта үткәч, яшь хезмәткәрләр, аспирант-галимнәр өчен махсус торак та төзелә башлаячак. Бүгенге көндә булган диссертацион советлар үз эшчәнлекләрен 2013 елның 1 июленә кадәр дәвам итәчәк, аннары зур кыскартулар көтелә. Киләчәктә укытучыларның хезмәт хакы буенча да үзгәрешләр булырга мөмкин. Укытучылар белән конракт төзеләчәк, анда нәрсә эшләргә тиеш, ничек түләнә – барысы да язылачак. Шулай ук укырга кабул итү, лаборантларның хезмәт хакы, махсус психологик консультация үзәге ачу турында да сораулар яңгырады. Ректор аларга тулы җавап биреп, тәкъдимнәрнең һәркайсын яхшылап тикшерәчәген әйтте һәм мондый очрашуларның даими рәвештә уздырылачагын җиткерде.

**Бездә кунак бар**

# Ирек тә чикләнгән булырга тиеш!

**Башы 1нче биттә.**

Иван Анатольевич сүзләренчә, моннан ун ел элек бу өлкәдә бөтен Россиядә егермеләп кеше генә кандидатлык диссертациясе яклаcreated, хәзер ел саен аның күз алдында гына 15-20 аспирант фәнни дәрәҗә ала. Галимнәрнең күбәюе, әлбәттә, әлеге өлкәнең әһәмияте артуын күрсәтә.

Мәскәүдән килгән галим хәзерге вакытта Дәүләт Думасы тарафыннан РФ Гражданнар кодексының дүртенче кисәгенә кертеләчәк канун проектлары белән таныштырып үтте. Аны бигрәк тә яңа кертеләчәк «ирекле лицензия» борчый. Ирекле лицензия – хокукка ия булучының башка затка аерым бер вакыт аралыгы, аерым бер шартларда башкаларга да интеллектуаль милектән кулланырга рөхсәт бирү. Мондый лицензияне депутатлар хокукка ия булучыга бирергә җыена. Бу канунга төрле иҗтимагый оешмалар тискәре мөнәсәбәтен белдергән. Иван Близнец шәхсән, мондый хокукны авторларга гына бирергә кирәк ди. Башкача булса, авторларның иҗат итү теләге калмаячак икән.

Иван Близнец әйтүенчә, РФ ГКның дүртенче кисәгенә нигездә дүрт төрле өлкәгә кагылышлы үзгәрешләр әзерләнә. Беренчесе мәгълүмати технологияләр үсеше шартларында кертергә кирәкле булган үзгәрешләр. Иң элек канунда сайт төшенчәсен булдырырга кирәк. Шулай ук, авторлар һәм интеллектуаль милек ияләренең хокукларын арттыру, канунНардагы бушлык-пробелларны бетерү, интеллектуаль милекне барлыкка китерү һәм куллану тәртипләре өлкәсендә үзгәрешләр булачак.

Бүгенге көндә авторлык хокукларын саклауда заманча технологияләр, бигрәк тә интернет челтәре комачаулык итә. Моңа мисал итеп, бер танышын китерде. Интеллектуаль милек академиясендә эшләгән бер галимнең китабы санкцияләнмәгән килеш интернетта пәйда була. Ни хикмәт, кыска гына вакыт эчендә ул китапны 22 мең кеше үз санагына күчерә. Әгәр шул китабын аз гына хакка булса да сатса, авторга күпме табыш килер иде.

Интернет челтәрендә еш утырган кешеләргә яхшы таныш булган Антон Осипов бер җыелышта, авторлык хокукы турындагы закон иң зыянлы закон дигән икән. И.Близнец юристларга болай фикерләүнең дөрес түгеллеген аңлатты. «Без – юристлар, автор хокукының никадәр әһәмиятле булганлыгын беркайчан да онытмаска тиеш!» – дип белдерде галим. Гел ирекне генә яклау дөрес түгел. «Ирек чикләнмәгәндә хаоска китерә», – ди ул.

Быел илебездә беренче патент турындагы канун кабул ителгәнгә ике йөз ел. Галимне бу юбилей турында бик сирәкләр генә белүе, киң җәмәгатьчелеккә чыкмавы борчый.

Россия Дәүләт интеллектуаль милек академиясе ректоры, шулай ук, үзенең халыкара тәҗрибәсе белән урталкашты. Интеллектуаль милек хокукы – беренче чиратта халыкара нормалар белән идарә ителгән бердәнбер өлкә икәнен билгеләп үтте.

Чыннап та, Иван Близнец сүзләрендә хаклык зур. Әгәр авторлык хокуклары булмаса, хәзер язып утырган мәкаләмнең дә мәгънәсе булмас иде. Автор хокуклары ихтирам ителгәндә, җәмгыятебездә язучылар да, уйлап табучылар да, журналистлар да булачак!

**Фән дөньясында**

# «Фикерле белә торган студентлар кирәк!»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

11 декабрь көнне Казан федераль университетының Тарих институты кунаклар кабул итте. Очрашу Е.И. Устюжанинның тууына 110 ел (1902-1968) һәм К.Р.Синицинаның тууына 80 ел (1932-1997) тулу хөрмәтеннән үткәрелгән Россиякүләм фәнни-гамәли конференция кысаларында оештырылды. «Мәктәпнең тарих дәреслеге: концептуаль һәм фәнни-методик проблемалар» җыены тарих дәреслекләрен төзү, тарих фәнен укыту мәсьәләренә багышланган иде.

Фән һәм техника алгарышы заманында яшәгән һәркем бу дәвернең таләпләренә туры килергә тиеш. Моның өчен гыйлемле булырга кирәк. Белүебезчә, белемнең иң төп өлеше, нигезе мәктәптә салына. Шуңа күрә дәреслекләр темасы – бүгенге көндә аеруча актуаль мәсьәлә. РФ һәм РТ атказанган фән эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, профессор Алтер Литвин үзенең чыгышында «Кичә генә мәктәпне тәмамлаган беренче курслар белән имтиханда очрашканда күңелсез бер хәлгә юлыгабыз: алар БДИга әзерлек вакытында тестлы биремнәр эшләргә шулкадәр күнеген бетәләр ки, бөтен нәрсәгә дә «әйе» яки «юк» дип кенә җавап бирәләр. Ә безгә, үз чиратыбызда, фикер йөртә һәм аны дәлилли белә торган студентлар кирәк», – дип билгеләп үтте.

Бу конференция быел җиденче мәртәбә үткәрелә. Монда илебезнең төрле шәһәрләреннән җитмешләп кеше катнашты. Чарага Е.И.Устюжанинның малае Евгений Устюжанин да чакырылган иде. Ул әтисе турында: «Әтинең тарих фәненә керткән өлеше турында аның башкалар алдындагы дәрәҗәсеннән күренә. Ул ТРның атказанган фән эшлеклесе. Бу кинң җәмәгатьчелек алдындагы абруй күп нәрсә турында сөйли», – диде.



Конференцияне ачып җибәргәннән соң, галимнәр әзерләп килгән докладлары белән чыгыш ясады. Тикшерелгән мәсьәләләрнең саны бик күп: теориягә, методикага, ягъни җәмгыятебез үзгәргән чорда мәктәптә һәм югары уку йортларында тарих фәнен яңа ысуллар белән укытуга кагылышлы сорауларга җаваплар эзләнде. «Заманча принцип һәм анализ карашыннан, безнең хәзерге заманча дип саналган дәреслекләребездә әлли нинди яңалыклар юк. Яңа төр дәреслекләргә түбәндәге сыйфатлар хас булырга тиеш: автор текстыннан катгый рәвештә баш тарту; укучыны һәрдаим дискуссияләргә җәлеп итү; дәреслекне укучы аның аркылы узган заман мохитен тоярлык итеп төзү; укучының фикерләү сәләтен булдыру йөзеннән тарихи чыганаклардан куллану һәм күреп аңлауга да игътибарны арттыру. Бездә исә, кызганыч ки, бу әйберләр җитеп бетми», – дип әйтеп узды чыгышында тарих фәннәре докторы, К.Д.Ушинский исемендәге Ярослав дәүләт университетының җәмгыять дисциплиналары һәм укыту методикасы кафедрасы әйтәкчесе Андрей Соколов.

Эшләнгән эшләр күп булса да, житешсезлекләребез дә байтак икән. Киңәшләр, әйтеләсе сүзләр күп булды, җиң сызганып эшлисе генә кала.

**Очрашу**

# «Ел студенты-2012» финалистлары кемнәр?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

10 декабрьнең салкын кичендә «Ел студенты-2012» конкурсы финалистларын Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгында җыеп очрашу үткәрделәр. Бу чарага хәбәрче булarak кына түгел, ә номинациядә җиңүче буларак бару икеләтә рәхәт иде. Чөнки безнең «Дарелфөнүн» газетасы да финалда бит!

Залда утырган һәркем үзен җиңүче дип атарга хокуклы! Аларның ике турны уңышлы үтеп, берничә кат иләк аша үткәрелеп, финалга эләгүләре – үзе бер зур сынау үтү белән бер. Кичәдә ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасары Рөстәм Гарифуллин һәм һәр номинациянең жюри әгъзалары килүе очрашуның никадәр җитди булуын билгели иде.

«Ел студенты» конкурсы сигезенче ел рәттән үткәрелә. Быел барлыгы 17 номинациягә 270тән артык гариза кабул ителгән. Төп номинацияләр «Ел студенты» һәм «Ел вузы».

Җиңүчеләр үзләренең эшчәнлеге белән таныштыру өчен, телевизион һәм радио тапшыруларга чакырылачак. Алар киң җәмәгатьчелеккә уңышларының серен чишәр. Экспертларның фикерләре, әлбәттә, гел уңай гына булмады. Катнашучыларга карата канәгатьсезлек хисләре дә җиткерелде. Мәсәлән, беренче турга җибәрелгән папкаларның күпчелеге нигезләнмәдәге таләпләргә туры килмәгән. Шуның аркасында лаеклы дип табылган эшләрне дә төшереп калдырырга мәҗбүр була алар. Югары уку йортларына караганда урта һөнәри белем бирү учреждениеләренең конкурста аз катнашуларына да басым ясалды.

Студентларның иң-иңнәрен сайлап алу өчен, ирешкән уңышларына, никадәр актив булуларына игътибар итәләр. Билгеле, лидерлык сыйфатларына ия булган студент матур итеп сөйли белергә генә түгел, ә үз сүзенә башкаларны ышандыра да белергә тиеш. Массакүләм мәгълүмат чараларын тикшергәндә дә таләпләр башкачарак. Беренчедән, басманың ни дәрәҗәдә үзенә җәлеп итүе исәпкә алына. Икенчедән, материалларның эксклюзив булырга тиеш. Гәҗитебезнең финалга үтүенең сәбәбе, әлбәттә, хезмәткәрләребезнең эшләренә җаваплы караулары һәм үз укучыларын профессиональ дәрәҗәдә җәлеп итә белүләрендәдер, мөгаен.

Конкурсны оештыручыларның берсе, ТР студентлар лигасы президенты Тимур Сөләйманов бүләкләү өлеше турында: «Ел студенты исеменә лаек булган студент үзе теләгән илнең теләсә-кайсы вузында «Алгарыш» программасы буенча уку бөхетенә ирешәчәк. Башка бүләкләр дә кыйммәтле, алга таба да стимул бирә торган булачак. Бәйрәм киче дә сюрпризларсыз булмас»,- дип белдерде. Чыннап та, бу кадәр кызыктыргач, икенче елга да катнашырлар инде. Тантаналы бәйрәм кичәсе бөтенроссия студентлар көнендә, ягъни киләсе елның 25 нче гыйнварында, булыр дип көтелә.

«Студентлар бер-берсе белән түгел, ә үз-үзләре белән ярышсыннар иде!» – дигән рухта очрашуга нокта куелды. Урамда салкын булуына да карамастан, килгән финалистлар кичәдән җаннарына җылы алып кайтып китте. Хәзер бергәләп зур ышыныч белән 25 гыйнварны көтәбез!

Әдәп-әхлак

# Хокукый культура

**Гали САФИН,**
юридик факультет студенты

*Әйтегез әле, кайсыбызның юл аркылы чыкканда кызыл утка туктап торганы бар. Мөмкинлек булса, үз-үзебезне куркыныч астына куеп алга йөгерәбез. Нишлисең, каядыр барасыбыз бар, ашыгабыз.*



Колак төбемдә машина сигналы яңгырады. Ярый, юл аркылы йөгереп чыгып өлгердем, юкса якты дөнья белән саубуллашмасам да, озак кына вакыт хастаханә тәрәзәсеннән карап ятарга туры киләчәк иде әле. Юл аркылы чыккан җәяүлеләргә машиналар юл бирергә тиеш тиешен. Бу хакта Юл йөрү кагыйдәләрендә язылган...

Илебездә җинаятьчелек тә, хокук бозу очраклары да зур күләмдә дибез, ә моның шулай булуы һәрберебездән дә тора бит. Кемнәргәдер гаеп ату каныбызга сеңгән, анысы. Йә хокук саклау органнарын, йә полицияне гаепләгән булабыз. Әйтегез әле, кайсыбызның юл аркылы чыкканда кызыл утка туктап торганы бар. Мөмкинлек булса, үз-үзебезне куркыныч астына куеп алга йөгерәбез. Нишлисең, каядыр барасыбыз бар, ашыгабыз. Машинада йөргәндә дә тизлекне билгеләнгәненнән арттырып җибәрергә күп сорамыйбыз. Нәтиҗәсе аяныч тәмамланырга мөмкинлеген уйлап бетермибез, димәк. Сүгенә-сүгенә ЮХИДИ хезмәткәрләренә штраф түләп китәбез үзе. Ә моннан ни файда? Ярый ла, тагын шуларга очрап материаль хәлебезнең начарлануыннан куркып киметә төшсәк. Әле кайчагында зәңгәрле-кызыллы «мигалка» күргәч, каршыдан килүчеләргә машина «күзләрен» яндырып сәламлибез, «хәтәр» урынны – камераны үткәч, куаларсың, янәсе.

Боларның барсы да хокукый культурабыз түбән булудан киләдер. Хокук бозу очраклары безнең өчен гадәти хәл, моңа беркемнең дә әлләни исе китми. Андый вакыйгалар юл хәрәкәтендә генә күзәтелми, ә тормышның бөтен өлкәләрендә дә еш очрый. Елга янына чүп түгү дисеңме, җәмәгать урыннарында тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр эчү дисеңме... Саный китсәң буа буарлык. Кайберәүләр, бездә кануннарны үтәү өчен түгел, ә аларны бозу өчен чыгаралар дияр. Тик кодексларда, башка кануннарда аңлашылмый торган урыннары сирәк. Хокукый пробеллар бөтен илләргә дә хас ул. Бусы инде башка мәсьәлә. Канун чыгаручылар шул ук кешеләр бит инде. Кеше – адәми зат хаталанмый булмас, бөтенесен күреп тә бетермәскә мөмкин. Ул органнарда тәҗрибәле депутатлар, юристлар эшли һәм алар моны берүзләре генә уйлап чыгарып утырмый. Шуңа анда киткән төгәлсезлекләр диңгездәге бер тамчы кебек кенә. Бер мисал китерим әле. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында кораллы алман солдатлары хәрби задание бирелгәч тә, бер поездга утыра алмый калганнар. Нигә дисезме? Чөнки кондуктор алардан билетлар сораган. Алар без түләүсез йөрергә тиеш дип вагонга кермәгәннәр, ә берәм-берәм билет алырга тотынганнар. Билет җитмәгәннәре икенче поезд көтеп, утырмыйча калган.

Кыскасы, безгә хокукый культураны үстерү өчен күп көч куярга кирәк. Бу илебездә хокук бозу вә җинаять очракларын бермәбер киметер иде, минемчә. Моның өчен нишләргә, дисезме? Минем тәкъдимем бик гадәти яңгырар, мөгаен. Әйдәгез, бары тик яшел ут кабынгач кына юл аркылы чыга башлыйк!

Ана теле

# Практикада күргәннәрем, сезгә сөйлим белгәннәрен…

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Мәкаләмнең исеме көлкеле тоелса да, язарга теләгән фикерем шактый җитди. Ике-өч атна элек безне (КФУның татар филологиясе бүлегенең 5 курс студентларын) Казанның төрле мәктәпләренә тараттылар. Сәбәбе дә гап-гади: практика үтәбез. Фираз Харисовның рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасын, Гөлнур Шәйхетдинова инглиз теле укыту, Роза Асылгәрәева һәм Әлфия Мотыйгуллинаның татар теле һәм әдәбиятын укыту методикаларын саллы гына үзләштергәннән соң, мәктәп укучылары белән күзгә-күз очраштык. Башка төркемнәрдән аермалы буларак, без балаларга инглиз теленнән дә дәресләр бирәчәкбез. Татар теленә караганда чит телне укыту күпкә авыррак дип исәпләгән идек. Ни дисәң дә туган тел – кечкенәдән өйрәнеп, сөйләшеп үскән тел, ә чит телне 5 ел дәвамында укып кына ана теле дәрәҗәсендә камил белеп бетерү мөмкин түгел. Балаларның да уйлаулары бөтенләй икенче төрле бит, тикшереп карау максатыннан кирәксә- кирәкмәсә дә төрле темага сораулар бирергә мөмкиннәр. Бигрәк тә яшь апаларын тыңларга теләмәүчеләре!.. Дөресен генә әйткәндә, укыта башлаганчы башыбызда әнә шундый сораулар кайнады.

Әмма уйлаганнарымның нәкъ киресе килеп чыкты. Инглиз теленнән дәресләр биргәндә түгел, ә туган телебезне укытканда күбрәк авырлыклар белән очраштык. Укучылар белән мин өстәрәк сурәтләгән хәлләр татар теле закончалыкларын өйрәтергә теләгәндә килеп туды. Бу урында бераз тукталып алыйм әле.

Мәктәп – шаулы дөнья, анда барысы да гөрләп, һәрвакыт хәрәкәттә торырга тиеш. Бу өлкәдә эшләүчеләр, әлбәттә, балаларның гөжләп торган тавышларына игътибар итми инде, үз эшен эшли бирә. Практикабызның беренче көннәрендә коридорда балаларның каршыдан йөгереп китеп, чак кына бәреп китмәүләре безгә бераз сәер тоелса да, соңрак күнегелде. Сүз башым бит шуңа дигәндәй, беренче булып миңа инглиз теленнән дәрес бирергә туры килде. Төне буе хәзерләп, яхшылап өйрәнгән дәресем 45 минут эчендә «эх» дигәнче үтеп тә китте. Ләкин дәрестән соңгы хис-кичерешләр әйтеп бетергесез!!! Балалар белән шундый рухта эшләү теләге уянып киткәндәй булды. Икенче, өченче, бишенче һәм шул рәвешле балаларга чит телдән кергән дәресләрем үзенчәлекле, күтәренке атмосферада дәвам итте. Гаҗәп тә түгелдер, әмма укучыларым һәр сүземе күз дә йоммыйча тыңлап, кабатлыйсы урында кабатлап, һәрдаим эзләнүдә иделәр. Кыскасы, инглиз телен өйрәнергә теләкләре көчле! Ә иң мөһиме: балаларның фәнне яратып үзләштерүләреннән тәм табам, тагын да дәртләнеп эшли бирәм.



Яшь укытучы Зилә Фәсхиева укучылары белән. Автор фотосы

Әлбәттә, бу зур шатлык, әмма хәлләрнең аянычлысы татар теле дәресләрен укытканда булды... Язарга кул да бармый, ләкин дөресе шул: балалар татар телен үзләренә кирәк тапмый. Дәресләрдәге үле тынлык мине эчтән ашый иде, укучылардан сорауларыма җавап тартып ала алмау исә тәмам кәефемне төшерә... Нишләргә? Методика өйрәнгәндә балаларны кызыксындыру юлын табарга, уйлап чыгарырга, артист булырга һ.б.ларны өйрәндек. Ә бала кызыкмаса нишләргә? Туган телен өйрәнергә теләге булмаган балада ничек татар теленә мәхәббәт уятырга? Практика дәвамында мин бу сорауларга җавапны эзләргә тырыштым, кызыксындыру чараларын да булдырмадым түгел... Нәтиҗәсе бер дә инглиз теле дәресендәге кебек түгел...

Мөгаен, мондый ситуация, беренче чиратта, гаиләдәге аралашудан һәм барыннан да бигрәк сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә килеп туадыр. Ике дәүләт теле булган Республикабызда татар телен өйрәнүнең плюслары күрсәтелми, ә чит тел өйрәнүнең карьерага, яңа аралашулар табарга, яңа илләрне күрү мөмкинлегенә ия булу көн саен искә алынып тора. Укучыларның баш миенә бу мәгълүмат чыгарып ташлый алмаслык дәрәҗәдә кереп утыра… Нәтиҗәсен үзем үк дәлилләп барам: татар теле дәресләрендә укучыларым мин татарча биргән сорауга басып русча җавап бирә.

Ә укытучы булу теләге исә миндә сүнде түгел, ә киресенчә кабынып китте. Шулай да ике телнең берсен укытырга сайла дисәләр, инглиз теленә тукталачагымны яшерүдән мәгънә юк...

Без тарихта эзлебез!

# «Кояш»ка 100 ел!

Моннан 100 ел элек Россиядә көн саен чыга торган «Кояш» исемле беренче татар газетасы дөнья күрә башлый. Ул 1912 елның 10 декабреннән башлап, 1918 елның 29 мартына кадәр укучыларын сөендерә.

«Кояш» газетасын бертуган Кәримовлар гамәлгә куя. Газета көн саен агентлыкларның программаларын, дөнья һәм Россия күләмендәге яңалыкларны бастыра. Газетаның үз хәбәрчеләре Казан һәм төбәктәге хәлләр турында да кызыклы мәкаләләр яза. Бәйрәмнәрдән соңгы көннәрне санамаганда, газета көн саен чыга. Ә башка төрле татар газеталары күп дигәндә атнасына 4 тапкыр басыла һәм рус газеталарының материалларына таяна. «Кояш»ның үзенчәлеге дә шунда: ул башка бер генә газетаны да кабатламый.

Редакция Амур номерларында урнашкан була. «Кояш» газетасын редакцияләү өчен, шәрыкны өйрәнү буенча югары белем алган Зәкәрия Садретдиновны чакыралар. Алты ел эчендә газетаның барлыгы 1245 саны дөнья күрә. Анда татар халкының мәшһүр шәхесләре Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан, Гасыйм Лотфи, Якуп Айманов, Ибраһим Бикколов һ.б. әдәби әсәрләре һәм мәкаләләре басыла.



**Котлыйбыз!**

*Газетабызда Әхмәтова фамилиясе күренми башласа, гаҗәпләнмәгез! Чөнки үткән җомга-шимбә көннәрендә хезмәттәшебез, Әгерҗе кызы Динара Әхмәтова белән Азнакай районы егете Рафыйк Миннекаевның туйлары узды. Рафыйк белән Динарага сәламәтлек, бәхет, мәхәббәт, тигез озын гомер телибез! Бөтен изге ниятләре тормышка ашсын!*

• Әдәби Ат

Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА



* * *

*Көлке хыялларны вакыт*
*таптый.*
*күңел генә көлми - көрсенә!*
*кайчак, язмыш, хыялланып*
*көткән*
*бер көнне дә безгә күпсенә.*

* * *

*Гайбәт сатып утырганчы*
*Кышкы озын кичтә,*
*Кулларыңнан көч киткәнче*
*Эшлә.*

* * *

*Нәфис сүзләр тезмәсен*
*ефәккә чиктем бүген.*

*Кулъяулыгым сиңа түгел.*

## Боз

*Тәрәзәгә чиртә-чиртә,*
*Боз яуды бүген.*
*Керфекләрең – киртә-киртә,*
*Яшерә күгең...*

*Яшь үләнне тишә-тишә*
*Боз ява тышта.*
*Яз иләслегенә сеңгән*
*Аптырау һушта.*

*Бит очларын чеметтерен*
*Коела күктән...*
*Җәйне уйлап, кышның барын*
*Оныттым күптән...*

## Без - горур татар кызлары

*Без – горур татар кызлары.*
*Коры хискә табынмыйбыз,*
*Юк-бар сүзгә кабынмыйбыз.*
*Бер сорарбыз – үтәмәсәң*
*Ялынмыйбыз.*

*Күңел – янартау булса да,*
*Күрсәтми тора беләбез.*
*Һичкайчан мескенләнмәбез.*
*Бер сорарбыз – каршы килсәң*
*Тезләнмәбез.*

*Авыр чакта ирен тешләп,*
*Түзәрбез без канатсак та.*
*Акыл белән йөрәгебез –*
*Безнең ике канат – сакта.*
*– Китмә, дустым, – дия алмабыз*
*Яратсак та...*

*Без – горур татар кызлары.*
*Милләт, дип, янып яшибез.*
*Мөһим түгел һич яшебез!*
*Бер әйтербез. Ә кабаттан...*
*Юк, дәшмибез.*

## Тәрәзләр елый

*Тәрәзләр дә елый бүген, мин генә түгел.*
*Әй, җанны өшеткән хәсрәт, яшь белән түгел!*

*Тәрәзләр дә елый әнә, син генә түгел!*
*Кара кайгыга уралып сулганмы бу гөл?!*

*Тәрәзләр дә яшен коя, ул гына түгел.*
*Нигә шулай шомлы җиһан, ник боек күңел?*

*Тәрәзләр дә үкси кебек, сез генә түгел.*
*Булмас дөньяны үзгәртеп, йә, учак, сүрел!*

*Тәрәзләр дә елый. Елый. Без генә түгел.*
*Яңгыр җирне яшәртә ди. Шунысын да бел...*

## Бәхет, диләр

*Бәхет, диләр, бәрхет, диләр,*
*Диңгезләрне гиздерә...*
*Бәхетне аңлый белмәсәң,*
*Бәхет тә бит биздерә...*

*Бәхет, диләр, байлык, диләр,*
*Бәхет, диләр, саулык ул.*
*Әгәр кадерен белмәсәң,*
*Бәхет тә бер айлык ул.*

*Бәхет, диләр, кояш, диләр,*
*Бәхет – тормыш кояшы.*
*Күңел күзең күрми икән,*
*Ул кояштан ни яхшы?*

*Бәхет, диләр, урман, диләр.*
*Кемгә чәчәк, кемгә үҗп.*
*Бер елмаерлык бәхет тә*
*Кемгә бик аз, кемгә күп.*

*Бәхет, диләр, бәхет, диләр,*
*Бәхет – яшәү тамыры...*
*Тамырларың ныкмы әле,*
*Әй син, туфрак камыры!*

## Бу бәхеткә исем кушып булмый

*Бу бәхеткә исем кушып булмый,*
*Бу бәхеткә хәтта... сүз җитми!*
*Аллаһыма шөкер – бар күңелдә*
*Касәсенә тулып җан түгелә,*
*Ярыймы, мин бу халәттән китмим?*

*Мин һәрвакыт шундый булыр идем,*
*Шулай яшәр идем һәр көнне!*
*Әгәр күңел шулай якты торса,*
*Бу бәхеттән һәрчак аң яктырса –*
*Ярдәм, изге гамәл эшләр өчен*
*Куяр идем бөтен көчемне...*

*Аптырыйм да кайчак башкаларга...*
*Мондый бәхет насыйп күпләргә!*
*Әмма бар да сукыр хисле бугай...*
*Ихлас тойсаң шушы бәхетеңне,*
*Яши алмас идең, карамыйча*
*Ходай сүзе, җиде күкләргә...*

*Белсәм дә мин бүген бәхет аша*
*авыр көннәр чират аласын,*
*Бүген минә каршы дәшә күңел!*
*Киләминем шушы яктылыкта –*
*Бу бәхеттә мәңге каласым!*

*Ә авырлык килсен, ансыз булмас,*
*Тик бәхет тә барсын янәшә.*
*Яме, Ходам?*
*Күкрәгемнән чыгып, көләч күңел,*
*Күккә карап, бүген мең дәшә...*

*Бу бәхеткә исем кушып булмый.*
*Бу бәхеткә хәтта... сүз җитми!*
*Авырлыклар килсә килер инде,*
*Ходай безне сынар, ә мин хәзер*
*Бу бәхеттән китмим!*

• Сәламәтлек

# Кара тмин

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

«КАРА ТМИН ҮЛЕМНӘН БАШКА БАРЛЫК АВЫРУЛАРГА ДА ДӘВА»
(ХӘДИС-ШӘРИФ)

Азия, Африка, көнчыгыш илләрендә кара тмин киң кулланышта йөри. Халык медицинасында аның орлыклары һәм мае искиткеч дәва буларак ашказаны, йөрәк, күз, сулыш юллары, бөер, бавыр, баш авырту һ.б. чирләрне дәвалау максатыннан файдаланыла. Хәтта кайбер табибларның тиешле дәвалау процесслары ярдәм итмәгән авырулар да, тмин белән шифалану курслары үткәннән соң, үзләрен яңадан туган кебек хис итәләр.

Көнчыгыш медицинасы исбатлаганча, кара тмин иммунитетны яхшырта, организмга энергия һәм көч бирә. Бу аның составында йөзләрчә микроэлементларның һәм кеше яшәсен өчен кирәкле витаминнарның барысы бергә булуына бәйле. Организмны гомуми ныгыту өчен ашаганнан соң 1 чәй кашыгы кара тмин мае эчеп кую да җитә (бу көнлек доза һәм аны арттырырга ярамый). Дәвалану курсы ике айга кадәр дәвам итәргә мөмкин. Хәтта рекламаларда күрсәтелә торган иң кыйммәтле җыерчыкларны тигезли торган бит кремнары составында да бу гаҗәп үзлекләргә ия булган үсемлекне күрергә була. Биттәге сыткы, экзема, чәч коелу ул, бетчәләргә каршы кулланган очракта да тиз ул арада үз нәтиҗәсен бирәчәк. Чөнки кара тмин аллергиягә каршы торучанлыкка ия.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт(с.г.в)нең



шундый хәдисе бар: «Кара тмин барлык чирләрдән дә дәва була ала, үлемгә генә дәва түгел...» (Бохари; Мөслим). 1400 елдан артык элек әйтелгән бу сүзләрнең төбенә төшү максатыннан, 1959 елда университет галимнәре төрле кара тминны ныклап тикшерә башлаганнар. Ни гаҗәп, ясаган ачышларда аның бугаз бизенә (зобка каршы) нык тәэсир итүе ачыкланган. Белүебезчә, бугаз бизе организмны саклау көченә ия булган иң әһәмиятле органнарыбызның берсе. Ә бу, үз чиратында, бөтен организмга файдалы дигән сүзләргә дәлил булып тора.

Бик күп тәҗрибәләрдән соң, АКШта хәтта кара тмин белән генә дарулар ясау лабораториясе ачылган. Анда бүгенге көндә составына шушы үсемлек кергән меңнәрчә дару ясыйлар. Бик күп еллар элек аның хикмәтле булуын әйтеп калдыру юктан гына булмаганлыгын аңлап, мөселманнар инде кара тминны көндәлек режимнарының бер өлешенә махсус рәвештә кертәләр. Миңа калса, үзебезнең сәламәтлегебезне ныгытыр өчен кара тмин белән файдалану бер дә зыянга булмас. Сәламәт тәндә сәламәт акыл булуын онытмасак иде!

# Димага ярдәм кирәк!



Бүгенге көндә КФУның Филология һәм сәнгать институның 3 курс студенты Дмитрий Жилин яшәү белән үлем арасында! Дмитрийның хәле бик авыр. Хәзер ул Мәскәүнең В.И.Шумаков исемендәге трансплантология һәм ясалма органнар федераль үзәгендә бавырын күчереп утырту буенча чират көтеп ята. Әлбәттә, моның өчен тиз арада бик зур суммада акча җыярга кирәк. Ә финанс чыгымнарын күтәрү Дима гаиләсенең генә хәленнән килми.

Сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы Диманың әнисенә ярдәм йөзеннән операциягә акча җыя башлады. Яшь егетнең сәламәтлегенә битараф булмаганнар кафедраның лаборанты Айгөл Габдрахмановага мөрәҗәгать итсен! Филология һәм сәнгать институтының башка бүлекләрендә дә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен махсус чаралар үткәрелер дип көтелә. Бу яшьтә әле тормыш башланырга гына тиеш, әмма ни кызганыч кемдер өчен ул көтелмәгән борылыш ала. Сәламәтлектән дә кадерлерәк нәрсә юк! Егетнең язмышына битараф калмасагыз иде! Ярдәм итәргә теләүчеләр түбәндәге адреска мөрәҗәгать итә алалар:

Казан, Межлаук урамы, 3/45, филология һәм сәнгать институты КФУ №31, 423 кабинет. Телефон: 221-34-99.

• Шигъри башваткыч

## Мыеклы ребус

Ринат НУРУЛЛИН

*Саннар мыексыз булса да,*
*Ребус мыеклы була.*
*«КЫЕК + МЫЕК + СЫЕК = СЫЗЫК», –*
*Дип шул ребус языла.*

*Цифрларның унысы да*
*Катнашмый бу ребуста.*
*Хәрефләрне цифр белән*
*Алмаштыр, булсаң оста.*
*(Ике чишелеше бар.)*

*Узган санда чыккан башваткычның җаваплары:*
*15703 + 92703 = 108406;*
*12703 + 95703 = 108406;*
*15304 + 92304 = 107608;*
*12304 + 95304 = 107608;*
*15403 + 92403 = 107806;*
*12403 + 95403 = 107806.*

! *Җиңүчебез янәдән Алинә ГАНИЕВА. Автографлы шигырь җыентыгы да аңа! Ул ребусның 4 җавабын белгән. Нурсөя МИНЗИНА беренче булып җибәрсә дә, 1 генә җавапны язган. Аңа лигада 8 очко бирелә. Лига турында мәгълүматны vk.com/darelfonyn адресы буенча белә аласыз.*

*Хөрмәтле укучылар! Ребустагы КЫЕК + МЫЕК + СЫЕК = СЫЗЫК тигезләмәсен хәрефләр урынына саннар куеп чишегез. Җавапларны киләсе атнаның чәршәмбесенә кадәр безнең электрон почтага җибәрергә мөмкин.*

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.